РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16 март 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге
Советының 2020 елга Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге
бюджеты үтәлеше турында" карары проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Түйкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставыныц 19 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл Советының 2012 елның 20 апрелендәге 34 номерлы (18.02.2015 № 103, 10.09.2015 № 133, 09.03.2016 № 27-10 карарлар редакциясендә) карары белән кабул ителгән авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының «2019 елда Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннан карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегенец 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2021 елның 08 апреле 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны-Түйкә авылы мәдәният йорты.
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423302 ТР, Азнакай районы, Түйкә авылы, Җәлили урамы, 19 нчы йорт.

4. Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының "2020 елда Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча, гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Советының "2020 елда Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын (1 нче кушымта) Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2021 елның 18 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Түйкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru , Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru// 2021 елның 18 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Закирова Р.Р.